# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Рус Пакшины авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 3 «14» октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче матдәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 матдәсе, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Рус Пакшины авылында 2024 елның «14» октябрендә узганү зарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Рус Пакшины поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга 2025 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Рус Пакшины поселогында һәйкәлне ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Рус Пакшины поселогында авыл клубының иске бинасын сүтү);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Рус Пакшины поселогында урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау( Рус Пакшины поселогында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру):

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 41 кешекертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 41 кеше, 100% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүленде:
«РИЗА» позициясеөчен  41 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясеөчен 0 граждан тавыш бирде;
Бәянителгәннәрнигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:
1.Гражданнарның үзарасалымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Рус Пакшины авылында  узган гражданнар җыенын - уздырылган,  нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Рус Пакшины авылында түбәндәге сорау буенча  узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Рус Пакшины  поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга 2025 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Рус Пакшины поселогында һәйкәлне ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Рус Пакшины поселогында авыл клубының иске бинасын сүтү);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Рус Пакшины поселогында урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау( Рус Пакшины поселогында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3. Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларыРегистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина